| | |
|---|---|
| ГЛАВА ЧУКМАРЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЧУКМАРЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2024ел, 5 ноябрь** **№ 3**

Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Чукмарлы авылында 2025 елда үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге Уставының 18.1 маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы карар кабул итте:

1. 2024 елның 19 ноябрендә 10.00 сәгатькә Сарман муниципаль районы Чукмарлы авылы, Совет урамы, 41 нче йорт адресы буенча урнашкан Чукмарлы авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез 2025 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы? Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Чукмарлы авыл җирлегендә, I төркем инвалидлардан, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге булектэ белем алучы студентлардан тыш, хәрби хезмәт, махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан тыш алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп баручы, түбәндәге эшләрне башкару буенча:

1)Чукмарлы торак пунктында урамнарда яктырту җайланмасы (лампаларны, энергияне сак тотучы тотучы яктырткычларны сатып алу һәм урнаштыру);
2)Чукмарлы торак пункты территориясен төзекләндерү (мәдэният йорты территориясенен тротуарын ремонтлау,мэгълүмэт стенды урнаштыру, территорияне кышкы чорда кардан чистарту,ягулык- майлау материаллары сатып алу, МТЗ-82 тракторына эленмэ жайланмалыры очен запчастьлар сатып алу);
3)Чукмарлы торак пунктында су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин

итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су җыю манарасын ремонтлау)
4) Чукмарлы торак пунктында һәйкәлләр төзү, аларны ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (газон чапкыч өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм керү юлын ремонтлау).

“ЭЙЕ” “КАРШЫ".

3.Әлеге карарны 7 көн эчендә «Сарман муниципаль районы» , муниципаль берэмлекнен рэсми сайтына, «Интернет мәгълүмат» теле коммуникация челтэрендэ, Чукмарлы жирлеге стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә,
4. Әлеге карар игълан ителгэн көннән үз көченә керә.

Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы
Сарман муниципаль районы: И.Х. Һадиуллин